СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2020 елның 30 январе № 42/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 14 ноябрендәге 39/7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«9. 2022 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре тиешле муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларына «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кергән очракта (урта гомуми белем булган очракта) куелмый.»;

түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктны өстәргә:

«10. 2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, юнәлеш буенча ике елдан да ким булмаган эш стажына карата таләп итеслә. 2020 елның 1 октябреннән соң Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында кодексының 8 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктында каралган әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре 2020 елның 1 октябренә кадәр вазыйфага билгеләнгән һәм әлеге

Нигезләмәдә каралган квалификация таләпләренә туры килә торган муниципаль хезмәткәрләргә кулланылмый.».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына кандидатураларны караганда, әлеге карарның 1 пункты белән расланган квалификация таләпләренә таянып эш итәргә.

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге Карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров